

Үткән атнада  Торбеево районы Татар Йонә гомуми топ белем бирv мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучыларынын районара семинары vтте. Семинар «Укучыларнын телдән сойләм кvнекмәләрен vстерv, белемнәрен гамәли файдалану» темасына багышлангпн иде.
Йонә топ мәктәбенен татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әльфия Фатих кызы Агишева 8нче сыйныфта Абдрахман Абсалямовнын «Ак чәчәкләр» романы буенча ачык дәресне унбер татар теле укытучыларына кvрсәтте. Дәрес югары дәрәҗәдә vтте.       Дәрестә укучыларнын телдән сойләм кvнекмәләре vстерелде, белемнәре гамәли файдаланылды, мәгълvмати технологияләрдән нәтиҗәле файдаланылды; дәрес методик яктан дорес һәм практик унышлы булды.
Укытучылар белемнәре белән семинарнын теоретик олешендә уртаклаштылар.
Атюрьево районы Усть-Рахмановка татар теле һәм әдәбияты укытучылары укучыларнын телдән сойләм кvнекмәләрен vстерv, белемнәрен гамәли файдалану алымнары турында сойләделәр. Чыгыш ясады Наилә Ахметхан кызы Хасьянова. Кvрше авылы Сыркыды мәктәбе укытучысы Светлана Ростәм кызы Мустафинанын 9 сыйныф укучысы Зульфия Бахтеева һәм Йонә мәктәбе 7нче класс укычысы Агишева Диана презентацияләрен кvрсәттеләр. Аннары мәктәп музеенда экскурсия vтте.
Семинарда Торбеево мәгълvмати-методик vзәк методисты Нужина Раиса Ильинична катнашты, яналыклар белән таныштырды һәм ин кvнеллесе Альфия Мәхмvт кызы Агишевага Хормәт грамотасы тапшырды. Һәркемгә иҗат унышлары теләп семинар эшен йомгаклады.

**Тәнзилә Агишева,**
*Т.-Юнки мэктэбе директоры*